**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 23 ноябре** **№ 17**

**Кама Тамагы муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга куллануга һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте Исемлегенә кертелгән мөлкәт белән эш итү тәртибе һәм шартлары турында" 2020 елның 25 мартындагы 253 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Кама Тамагы муниципаль район Советының "Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга куллануга һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәте Исемлегенә кертелгән мөлкәт белән эш итү тәртибе һәм шартлары турында" 2020 елның 25 мартындагы 253 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. югарыда күрсәтелгән карарның исемендә һәм 1, 2 пунктларында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

2. Нигезләмәнең атамасында “кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче” сүзләреннән соң “, махсус салым режимын кулланучы физик затларга” сүзләрен өстәргә;

Нигезләмәнең 1.1 пунктында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «,индивидуаль эшкуарлар

булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

2.2.3 пунктның 1.3 пунктында «белешмәләре кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның бердәм реестрында булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар» сүзләрен «белешмәләре кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар турында белешмәләр булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар һәм оешмалар реестрында булган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.3.1 пунктта «Кама Тамагы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүнең муниципаль программасы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4.5 пунктта «яисә үзләренең күрсәтелгән Федераль законның 4 статьясындагы 5 өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертү шартлары турында» сүзләреннән соң « яисә махсус салым режимын кулланучы физик зат булуы турында» сүзләрен өстәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс һәм икътисадый үсеш мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**муниципаль район Советы рәисе: Н.А.Вазыйхов**